ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗАИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗӘЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

19.11.2020 г. Заинск № 520

**«2019-2021 елларга Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районында террорчылыкны һәм экстремистлыкны профилактикалау» муниципаль прог раммасын раслау турында» 2018 елның 20 ноябрендәге 1750 номерлы Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Россия Федерациясе Президенты тарафыннан 2018 елның 28 декабрендә(№ Пр-2665) расланган 2019-2023 елларга Россия Федерациясендә террорчылык идеологиясенә каршы тору комплекслы планы нигезендә, Татарстан Республикасында террорчылыкка каршы комиссиянең 2019 елның 06 маендагы ПР-109 номерлы утырышы беркетмәсенең 16 һәм 17.4 пунктларын үтәү йөзеннән, Зәй муниципаль районы Уставына таянып, Зәй муниципаль районында террорчылыкны һәм экстремизмны профилактикалауга юнәлтелгән чараларны камилләштерү максатларында, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты

**карар бирә:**

1. «2019-2021 елларга Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районында террорчылыкны һәм экстремистлыкны профилактикалау» муниципаль программасын раслау турында» 2018 елның 20 ноябрендәге 1750 номерлы Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Исемдә «2019-2021» саннарын «2019-2023» саннарына алмаштырырга»; карарның 1 пунктында «2019-2021» саннарын «2019-2023» саннарына алмаштырырга»;

1.2. Күрсәтелгән карар белән расланган «2019-2021 елларга Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районында терроризмны һәм экстремизмны профилактикалау» муниципаль программасында (алга таба – программа) исемдә «2019 – 2021» саннарын «2019-2023» саннарына алмаштырырга.

1.3. Программа паспортында:

«Муниципаль программаның исеме» юлында «2019 – 2021» саннарын «2019-2023» саннарына алмаштырырга.

«Муниципаль программаны үтәүдә катнашучылар» юлын түбәндәге үтәүдә катнашучылар белән тулыландырырга:

- авыл җирлекләре башлыклары (килешү буенча);
- Эчке эшләр министрлыгының Зәй районы буенча бүлеге (килешү буенча);
- Россия Федераль куркынычсызлык хезмәтенең Зәй шәһәрендәге бүлеге (килешү буенча);
- «Җәзаларны үтәтү федераль хезмәтенең ТР буенча идарәсе җинаять-башкарма инспекциясе» ФКУ Зәй муниципальара филиалы (килешү буенча);
- Россия Тикшерү комитетының Татарстан Республикасы буенча Тикшерү идарәсенең Зәй районара тикшерү бүлеге (килешү буенча);
- Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Зәйдәге социаль яклау бүлеге (килешү буенча);
- Татарстан Республикасы Хезмәт, мәшгульлек һәм социаль яклау министрлыгының Зәй шәһәре халыкны эш белән тәэмин итү үзәге (килешү буенча);
- «Зәй район үзәк хастаханәсе» ДАСУ (килешү буенча);
- «Форпост» МБУ (килешү буенча);
- дини, иҗтимагый, мәгариф һәм фәнни оешмалар (килешү буенча);

«Муниципаль программаны гамәлгә ашыру сроклары һәм этаплары» юлында «2019 – 2021» саннарын «2019-2023» саннарына алмаштырырга.

«Муниципаль программаны финанслау күләмнәре һәм чыганаклары» юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Муниципаль программаны финанслауның гомуми күләме 2265 мең сум тәшкил итә, шул исәптән гамәлгә ашыру еллары буенча:

- 2019 ел - 705 мең сум;
- 2020 ел - 450 мең сум;
- 2021 ел - 690 мең сум;
- 2022 ел - 210 мең сум;
- 2023 ел - 210 мең сум.

Муниципаль программаны финанслау чыганаклары - Зәй муниципаль районы бюджеты акчалары.

Муниципаль программа чараларын финанслау Зәй муниципаль районы бюджетында расланган ассигнованиеләр чикләрендә гамәлгә ашырыла. Муниципаль программаны гамәлгә ашыруга тотыла торган акчалар күләме район бюджеты, инфляция процесслары һәм Зәй муниципаль районы территориясендә икътисадый вазгыять мөмкинлекләреннән чыгып аныкланырга һәм төзәтелергә мөмкин».

1.4. «Муниципаль программаны гамәлгә ашыру сроклары һәм этаплары» IV бүлеген түбәндәге редакциядә бәян итәргә: “Муниципаль программа 2019-2023 елларга исәпләнгән, этапларга бүленми.”

1.5. «Муниципаль программаны финанс белән тәэмин итү» V бүлеген түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «2019-2023 елларга муниципаль программаны финанслауның гомуми күләме 2265,00 мең сум тәшкил итә, шул исәптән:

- 2019 ел - 705 мең сум;
- 2020 ел - 450 мең сум;
- 2021 ел - 690 мең сум;
- 2022 ел - 210 мең сум;
- 2023 ел - 210 мең сум.

Муниципаль программаны финанслау чыганаклары - муниципаль район бюджеты акчалары - 2265,00 мең сум».

1.6. «2019-2023 елларга Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районында террорчылыкны һәм экстремизмны профилактикалау» программасының максаты, бурычлары, нәтиҗәләрен бәяләү индикаторлары һәм программа чаралары буенча финанслау 1 таблицасын әлеге карарга 1 кушымта нигезендә яңа редакциядә бәян итәргә.

2. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталы»нда (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Зәй муниципаль районы сайтында урнаштырырга.

3. Карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

**Башкарма комитет җитәкчесе вазыйфаларын башкаручы** **М.И. Захарова**

Юрист
Т.В.Токмакова

**Кушымта 1**

# «2019-2023 ЕЛЛАРГА ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗӘЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНДА ТЕРРОРЧЫЛЫКНЫ ҺӘМ ЭКСТРЕМИЗМНЫ ПРОФИЛАКТИКАЛАУ» ПРОГРАММАСЫНЫҢ МАКСАТЫ, БУРЫЧЛАРЫ, НӘТИҖӘЛӘРЕН БӘЯЛӘҮ ИНДИКАТОРЛАРЫ ҺӘМ ПРОГРАММА ЧАРАЛАРЫ БУЕНЧА ФИНАНСЛАУ

| Төп чараларның исеме | Башкаручылар | Төп чараларны үтәү вакыты | Ахыргы нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары, үлчәү берәмлеге | Индикаторларның күрсәткече | | | | | Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы бюджеты хисабына финанслау- мең сумнарда | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| **Максат: Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы территориясендә яшәүче гражданнарның тормышларын һәм тынычлыгын, экстремизмга һәм террорчылыкка каршы тору нигезендә аларның законлы хокуклары һәм мәнфәгатьләре якланышы дәрәҗәсен күтәрү, Татарстан Республикасында экстремизм һәм террорчылык күренешләрен профилактикалау һәм кисәтү** | | | | | | | | | | | | | |
| **Бурыч 1. Террорчылык идеологиясе йогынтысына эләккән, шулай ук йогынтыга бирелердәй затлар белән профилактик эш өчен шартларны тәэмин итү** | | | | | | | | | | | | | |
| | | | | 2019 база елы | 2020 ел | 2021 ел | 2022 ел | 2023 ел | 2019 ел | 2020 ел | 2021 ел | 2022 ел | 2023 ел |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 13 | 14 | 15 | 16 | 17 |
| 1.1. «Аерым игътибар үзәгендәге» (хәвефле) категория затлар белән эшләү буенча муниципаль ведомствоара эшче төркемнең эшен тәэмин итү | ЗМР Башкарма комитеты,<br>Авыл җирлекләре башлыклары (килешү буенча);<br>Эчке эшләр министрлыгының Зәй районы буенча бүлеге (килешү буенча);<br>Россия Федераль куркынычсызлык хезмәтенең Зәй шәһәрендәге бүлеге (килешү буенча);<br>«Җәзаларны үтәтү федераль хезмәтенең ТР буенча идарәсе җинаять-башкарма инспекциясе» ФКУ Зәй муниципальара филиалы (килешү буенча);<br>Россия Тикшерү комитетының Татарстан Республикасы буенча | 2021-2023 еллар | Эшче төркемнәре утырышлары саны | 4 | 4 | 4 | 4 | 4 | - | - | - | - | - |

| | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | тикшерү идарәсенең Зәй районара тикшерү бүлеге (килешү буенча);<br>Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Зәйдәге социаль яклау бүлеге (килешү буенча);<br>Татарстан Республикасы Хезмәт, мәшгульлек һәм социаль яклау министрлыгының Зәй шәһәре халыкны эш белән тәэмин итү үзәге (килешү буенча);<br>«Зәй район үзәк хастаханәсе» ДАСУ (килешү буенча); | | | | | | | | | | | | |
| 1.2. «Махсус игътибар үзәгендәге» (хәвефле) категория затлар белән адреслы профилактик чараларда катнашу өчен коммерцияле булмаган (шул исәптән дини) оешмаларны һәм иҗтимагый активларны стимуллаштыру чараларын гамәлгә ашыру | ЗМР Башкарма комитеты | 2021-2023 еллар | Җәмәгать активистларын җәлеп итеп профилактик эш белән тәэмин ителгән “махсус игътибар” категориясе затлары өлеше | | | 50 | 60 | 70 | | | 10 | 10 | 10 |
| 1.3. «Аерым игътибар үзәгендәге» (хәвефле) категория затлар белән эшләүдә, аларның халәтен диагностикалау, психологик һәм психотерапевтик ярдәм күрсәтүдә катнашкан вазифаи затларны һәм иҗтимагый активларны әзерләү өчен квалификацияле белгечләрне җәлеп итүне | ЗМР Башкарма комитеты,<br>«Зәй район үзәк хастаханәсе» ДАСУ (килешү буенча); | 2021-2023 еллар | Җәлеп ителгән белгечләр саны | | | 2 | 2 | 2 | | | 10 | 10 | 10 |

| | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| тәэмин итү | | | | | | | | | | | | | |
| 1.4. Шәхси патронаж кысаларында яшьләр, спорт оешмалары, яшьләр иҗтимагый активистларының «аерым игътибар үзәгендәге» (хәвефле) категория затлар белән социаль характердагы өзлексез ярдәм чараларын тормышка ашыруда актив катнашуын тәэмин итү | «Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитетының яшьләр эшләре идарәсе» МКУ,<br>«Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы башкарма комитетының физик культура, спорт һәм туризм идарәсе» МКУ | 2021-2023 еллар | Күрсәтелгән хезмәтләр төрләре билгән «аерым игътибар үзәгендәге» (хәвефле) категория затлары өлеше | | | 15 | 20 | 25 | | | 10 | 10 | 10 |
| 1.5. Функциональ регламент белән беркетелгән белем бирү оешмаларының вазыйфаи затларының «аерым игътибар үзәгендәге» (хәвефле) категория затлар белән адреслы эш алып баруда актив катнашуын тәэмин итү | «ТР Зәй муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф идарәсе» МКУ | 2019-2023 еллар | Уку сыйныфларын да «аерым игътибар үзәгендәге» (хәвефле) категория затлары белем ала торган төркемле корректлаучы чаралар (тренинглар, семинарлар) саны | Не менее 2 мероприятий в год с одним классом | | | | | - | - | - | - | - |
| 1.6. Социаль хезмәт күрсәтү өлкәсе белгечләренең «аерым игътибар үзәгендәге» категория (хәвефле) гаиләләр белән профилактика чараларны тормышка ашыруда, шул исәптән торгызу медиациясе | Татарстан Республикасы Хезмәт, мәшгульлек һәм социаль яклау министрлыгының Зәй шәһәре халыкны эш белән тәэмин итү үзәге (килешү буенча) | 2021-2023 еллар | “Аерым игътибар үзәгендәге” категория (хәвефле) затлар яшәгән гаиләләрнең гомуми | | | +10% | +10% | +10% | | | 10 | 10 | 10 |

| | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| техникасын кулланып, актив катнашуын тәэмин итү | | | санынннан профилактик чараларга җәлеп ителгән гаиләләр өлеше | | | | | | | | | | |
| 1.7. Адреслы профилактик эштә катнашучы белгечләрнең һөнәри осталык буенча тармакара семинарларын үткәрү | «ТР Зәй муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф идарәсе» МКУ,<br>«Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитетының яшьләр эшләре идарәсе» МКУ,<br>Татарстан Республикасы Хезмәт, мәшгульлек һәм социаль яклау министрлыгының Зәй шәһәре халыкны эш белән тәэмин итү үзәге (килешү буенча),<br>"Зәй район үзәк хастаханәсе» ДАСУ (килешү буенча) | 2021-2023 еллар | Семинарлар саны | | | 1 | 1 | 1 | | | - | - | - |
| 1.8. Яшьләр арасында мәгариф, яшьләр, медицина, социаль яклау өлкәсенә социаль педагогларны, психологларны, психиатрларны җәлеп итү өчен һөнәри юнәлеш бирү эшен үткәрү, тиешле белем алу һәм муниципаль берәмлектә белгечлек буенча алга таба эшкә урнашу өчен мәгълүмати ярдәм күрсәтү | «ТР Зәй муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф идарәсе» МКУ,<br>«Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитетының яшьләр эшләре идарәсе» МКУ,<br>Татарстан Республикасы Хезмәт, мәшгульлек һәм социаль яклау министрлыгының Зәй шәһәре халыкны эш белән тәэмин итү үзәге (килешү буенча),<br>"Зәй район үзәк хастаханәсе» ДАСУ (килешү буенча) | 2021-2023 еллар | Күрсәтелгән тармакларда белгечләрне туплау проценты | | | +10% | +10% | +10% | | | - | - | - |
| 1.9. Террорчылык | «Татмедиа» АҖ филиалы (килешү | 2021- | Мондый | | | 5 | 10 | 10 | | | 10 | 10 | 10 |

| | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| идеологиясен ныклы кабул итмәүне формалаштыруга юнәлдерелгән чыгышларга аерым игътибар үзәгендәге (хәвефле) категория затларын җәлеп итү эшен алып бару һәм массакүләм мәгълүмат чараларында, социаль челтәрләрдә, гавами чараларда традицион Россия рухи-әхлакый кыйммәтләрен алга сөрү | буенча) | 2023 еллар | аңлатмалар белән чыгыш ясаган «аерым игътибар» (хәвеф) категориясе затлары өлеше | | | | | | | | | | |
| 1.10. Системалы хезмәт һәм уку процессларына җәлеп ителмәгән яшьләрне, шулай ук иҗтимагый әһәмиятле социаль проектларны һәм программаларны гамәлгә ашыру буенча формаль булмаган яшьләр оешмалары вәкилләрен чараларга тарту буенча эш алып бару | «Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитетының яшьләр эшләре идарәсе» МКУ | 2021-2023 еллар | Гомуми максатчан аудиториягә карата җәлеп ителгән яшьләр өлеше | | | +10% | +10% | +10% | | | 10 | 10 | 10 |
| 1.11. Интернет челтәрендә деструктив бергәлекләрдә муниципаль берәмлек халкының активлыгына мониторинг уздыруны тәэмин итү (катнашучыларны матди кызыксындыру) | «Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитетының Мәгариф идарәсе» МКУ,<br>«Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитетының яшьләр эшләре идарәсе» МКУ,<br>“Форпост” МБУ (килешү буенча) | 2021-2023 еллар | Мониторинг нәтиҗәләре буенча мәгълүмати белешмәләр саны | | | 12 | 12 | 12 | | | 10 | 10 | 10 |
| 1.12. Муниципаль берәмлектә таратыла торган материалларны даими | ЗМР Башкарма комитеты | 2021-2023 еллар | Үткәрелгән тикшеренүләр саны | | | 2 | 2 | 2 | | | 20 | 20 | 20 |

| | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| мониторинглауны оештыру һәм аларда экстремизм билгеләре булу-булмауга тикшерүләр уздыру | | | | | | | | | | | | | |
| 1.13. Дини оешмалар җитәкчелеге белән үзара хезмәттәшлектә Татарстан Республикасы өчен традицион ислам рәвешләрен тотучы рухи лидерларны әзерләү өчен Россиянең алдынгы теологик уку йортларына (Болгар ислам академиясенә) кандидатларны сайлап алу һәм җибәрү процедурасын оештыру | ЗМР Башкарма комитеты | 2021-2023 еллар | Җибәрелгән кандидатлар саны | | | 1 | 1 | 1 | | | - | - | - |
| **Бурыч 2. Татарстан Республикасы халкының террорчылыкка каршы аңын формалаштыру** | | | | | | | | | | | | | |
| 2.1. Мәгълүмат-пропаганда төркеме эшчәнлеген тәэмин итү | ЗМР Башкарма комитеты,<br>Авыл җирлекләре башлыклары (килешү буенча),<br>Зәй районы буенча Эчке эшләр министрлыгы бүлеге (килешү буенча), Россия Федераль куркынычсызлык хезмәтенең Зәй шәһәрендәге бүлеге (килешү буенча);<br>«Җәзаларны үтәтү федераль хезмәтенең ТР буенча идарәсе җинаять-башкарма инспекциясе» ФКУ Зәй муниципальара филиалы (килешү буенча);<br>Россия Тикшерү комитетының Татарстан Республикасы буенча | 2019-2023 еллар | Эшче төркемнәре утырышлары саны | 4 | 4 | 4 | 4 | 4 | - | - | 10 | 10 | 10 |

| | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | тикшерү идарәсенең Зәй районара тикшерү бүлеге (килешү буенча); Дини, иҗтимагый, мәгариф һәм фәнни оешмалар (килешү буенча) | | | | | | | | | | | | |
| 2.2. Террорчылыкка каршы юнәлешле күргәзмә агитация продукциясен (стикерлар, брошюралар, плакатлар) эшләү, әзерләү һәм тарату | ЗМР Башкарма комитеты, Авыл җирлекләре башлыклары (килешү буенча) | 2019-2023 еллар | Иҗтимагый игътибар өчен урнаштырылган продукция берәмлекләре саны | 5000 | +5% | +5% | +5% | +5% | 75 | - | 20 | 20 | 20 |
| 2.2.1. Кешеләр күпләп җыела торган урыннарда урнаштырылган тышкы реклама һәм җиһазлар чараларыннан файдалану | Район башкарма комитеты | 2019-2023 еллар | Тышкы реклама конструкцияләрендә урнаштырылган мәгълүмати-пропаганда материаллары саны (бер.) | 5 | 6 | 6 | 3 | 3 | 30 | 36 | 36 | 20 | 20 |
| 2.3.Матди кызыксындыруны күздә тотып, квалификацияле лектор-пропагандистларны халык белән мәгълүмати-аңлату эшләре алып бару өчен җәлеп итү | ЗМР Башкарма комитеты, Авыл җирлекләре башлыклары (килешү буенча) | 2021-2023 еллар | Җәлеп ителгән лекторлар лекцияләре/чыгышлары саны | | Яшьләр арасында 10 мең кешегә 1 чыгыш | | | | | | 10 | 10 | 10 |
| 2.4. Халык белән мәгълүмати-аңлату эшләре алып бару өчен лектор-пропагандистларның муниципаль активын әзерләүне тәэмин итү | ЗМР Башкарма комитеты, Авыл җирлекләре башлыклары (килешү буенча) | 2021-2023 еллар | Муниципаль берәмлек халкы арасыннан укытылган лекторлар саны | | | 2 | 2 | 2 | | | 10 | 10 | 10 |

| | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 2.5. Террорчылыкка каршы көрәштә теләктәшлек көненә багышланган иҗтимагый-сәяси, мәдәни һәм спорт чаралары үткәрү (3 сентябрь) | «Татмедиа» АҖ филиалы (килешү буенча) | 2019-2023 еллар | Чаралар саны | 30 | 30 | 35 | 40 | 40 | - | - | 10 | 10 | 10 |
| 2.6. "Экстремизмга юк" декадасын үткәрү (4-14 сентябрь) | ЗМР Башкарма комитеты,<br>Авыл җирлекләре башлыклары (килешү буенча),<br>Зәй районы буенча Эчке эшләр министрлыгы бүлеге (килешү буенча),<br>Дини, иҗтимагый, мәгариф һәм фәнни оешмалар (килешү буенча) | 2019-2023 еллар | Чаралар саны | 30 | 30 | 35 | 40 | 40 | - | - | 10 | 10 | 10 |
| 2.7. Муниципаль районда уяулыкны саклау һәм террорчылыкны һәм экстремизмны профилактикалауда катнашу мәсьәләләре буенча гражданнар җыеннары үткәрү | Авыл җирлекләре башлыклары (килешү буенча) | 2020-2023 еллар | Авыл җирлекләрендә җыеннар саны | | Бер авыл җирлегендә 0,5 җыен | | | | | - | - | - | - |
| 2.8. Террорчылыкка каршы эчтәлектәге мәгълүматны, шул исәптән видеороликларны эшләүне (сайлап алуны) һәм социаль челтәрләрнең муниципаль сегментында, район Интернет челтәренең башка мәгълүмат ресурсларында урнаштыруны тәэмин итү | «Татмедиа» АҖ филиалы (килешү буенча) | 2021-2023 еллар | Урнаштырылган материаллар саны | | | 1 | 1 | 1 | | | - | - | - |
| 2.9. Рәсми дини конфессияләр (православие, | «Татмедиа» АҖ филиалы (килешү буенча) | 2021-2023 | Мәкаләләр саны | | | 1 | 1 | 1 | | | - | - | - |

| | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| ислам) вәкилләренең террорчылыкка каршы тору эшендә ватандашларны берләштерүгә юнәлтелгән тематик вәгазьләрен массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгаруны оештыру | | еллар | | | | | | | | | | | |
| 2.10. Террорчылыкка каршы юнәлештәге документаль һәм сәнгати фильмнарны муниципаль берәмлекнең авыл клубларында һәм мәдәният йортларында даими күрсәтүләрне оештыру | “ТР Зәй муниципаль районы Башкарма комитетының мәдәният идарәсе»МКУ, | 2021-2023 еллар | Күрсәтелгән фильмнар саны | | | 10 | 10 | 10 | - | - | - | - | - |
| 2.11. Яшьләр арсында чемпионатлар, квестлар, түгәрәк өстәлләр, очрашулар, фестивальләр, конкурслар, акцияләр оештыру | «Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитетының яшьләр эшләре идарәсе» МКУ | 2021-2023 еллар | Чаралар саны | | | 5 | 5 | 5 | - | - | 10 | 10 | 10 |
| 2.12. Террорчылыкка һәм экстремизмга каршы көрәш өлкәсендә иң яхшы проектка (иҗат эшенә) конкурс үткәрү | «Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитетының яшьләр эшләре идарәсе» МКУ | 2021-2023 еллар | Конкурска гаризалар саны | | | 5 | 5 | 5 | - | - | 10 | 10 | 10 |
| 2.13. Коммуникатив күнекмәләрне арттыруга, татулык, милләтара һәм динара татулык идеяләрен популярлаштыруга юнәлдерелгән тематик түгәрәк өстәлләр, конференцияләр, | “ТР Зәй муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф идарәсе» МКУ | 2021-2023 еллар | Чаралар саны | | | 5 | 5 | 5 | - | - | 10 | 10 | 10 |

| | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| конкурслар, ата-аналар җыелышлары, сыйныф сәгатьләре, акцияләр, тренинглар оештыру | | | | | | | | | | | | | |
| 2.14. Үзара аңлашу, милләтара теләктәшлек, балаларның медиаиминлеге мәсьәләләрендә ата-аналарның белем дәрәҗәсен арттыруга юнәлдерелгән “Ата-аналар өчен университет» форматы кысаларында дәресләр үткәрү | “ТР Зәй муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф идарәсе» МКУ | 2021-2023 еллар | Профилактик дәресләрдә катнашкан ата-аналарның максатчан категориядәге балаларның гомуми өлешендә өлеше | | | 50 | 60 | 65 | | | - | - | - |
| **Бурыч 3. Муниципаль берәмлек карамагындагы объектларның террорчылыктан сакланышын көчәйтү** | | | | | | | | | | | | | |
| 3.1.Муниципаль объектларның террорчылыкка каршы тору дәрәҗәсен арттыру | ЗМР Башкарма комитеты;<br>“ТР Зәй муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф идарәсе» МКУ,<br>“ТР Зәй муниципаль районы Башкарма комитетының мәдәният идарәсе»МКУ,<br>“ТР Зәй муниципаль районы Башкарма комитетының яшьләр эшләре идарәсе» МКУ,<br>“ТР Зәй муниципаль районы Башкарма комитетының физик культура, спорт һәм туризм идарәсе» МКУ,<br>Мәгариф, мәдәният, спорт, яшьләр сәясәте өлкәсендә муниципаль оешмалар | 2019-2023 еллар | Муниципаль берәмлек карамагында булган объектларның террорчылыкка каршы чаралар белән тәэмин ителеше өлеше (%) | 70 | 75 | 80 | - | - | 600 | 414 | 464 | - | - |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| **Барлыгы Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы бюджетыннан** | 705 | 450 | 690 | 210 | 210 |
| **Муниципаль программа буенча барысы** | | | 2265 | | |

Зәй муниципаль районы башлыгы ярдәмчесе,
район террорчылыкка каршы комиссиясе секретаре Т.